# Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
# 4 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен
# татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре
# (2015/2016 нчы уку елы)

**Үткәрү вакыты - 3 сәгать** **Максималь балл - 48**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. 4 нче сыйныф дәреслегенең 3 нче битендәге ***(2 балл)***

Исәнмесез, минем шаян дуслар!
Хуш килдегез, рәхим итегез!
Кулга тотып белем ачкычларын,
Я, әйдәгез, түрдән үтегез!

дип башланган шигырьнең авторы –
а) Абдулла Алиш;
ә) Габдулла Тукай;
б) Шәйхи Маннур;
в) Муса Җәлил.

2. *Күл төбендә, төпсез тирәнлектә,* ***алтын урак*** *ялтырап ята* (Г. Сабитов) җөмләсендәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең күчерелмә мәгънәсе нәрсәгә нигезләнгән? ***(2 балл)***
а) күренешнең төсенә;
ә) күренешнең формасына;
б) күренешнең башкарган эшенә;
в) күренешнең урынына.

3. Табышмакның дөрес җавабын билгеләгез. ***(2 балл)***

Күренми дә, тоттырмый да.
Үзе – хәнҗәр, үзе – ук.
Аннан ачы, аннан татлы,
Аннан хәтәр нәрсә юк.

а) акыл;
ә) җил;
б) сүз;
в) күз карашы.

4. *Кайда су һәм дымлык булса, анда яшеллек, күңеллелек,* ***хәят*** (Г. Тукай) җөмләсендә билгеләнгән сүзнең мәгънәсе – ***(2 балл)***
а) тормыш;
ә) кеше;
б) тараф;
в) болын.

5. *Сал* сүзенең мәгънәсе – ***(2 балл)***

а) саламнан ясалган җәймә;
ә) су буйлап агызу өчен бер-берсенә беркетелгән бүрәнәләр;
б) кечкенә пароход;
в) җилкәнле көймә.

6. Татар алфавитында ике авазга билге булып йөри торган хәрефләр ничә? ***(2 балл)***
а) 2;
ә) 3;
б) 4;
в) 5.

7. Тамырдаш сүзләр арасындагы артык сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) көйли;
ә) көйче;
б) көймә;
в) көйле.

8. Кайсы сүз сүзлекләрдә теркәлми? ***(2 балл)***
а) бакча;
ә) бакчачы;
б) гөлбакча;
в) бакчабыз.

9. Мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) га-дел-сез-лек-не;
ә) бала-лар-ыбыз-га;
б) кош-чык-ла-ры-быз;
в) ти-мер-че-лек-тәге.

10. Күплек санда -нар/-нәр кушымчасы ялгана торган исемнәрне билгеләгез. ***(4 балл)***
а) көн;
ә) иртә;
б) дус;
в) ел;
г) шәһәр;
д) таң;
е) белем;
ж) туган.

11. Хаталы сүзтезмәне билгеләгез. ***(2 балл)***
а) унсигез малай;
ә) ике йөз укучы;
б) уналты балалар;
в) сигез урын.

12. Җөмләдә кулланылырга тиешле бәйләүче сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
*Миңа милли ризыклар ... китап кирәк.*
а) белән;
ә) өчен;
б) өстендә;
в) турында.

13. “Татар әдәбияты” темасына караган җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Татар халкының тарихы зур һәм катлаулы.
ә) Мин сынлы сәнгать белән кызыксынам.
б) Рудольф Нуриев күренекле биюче булган.
в) Ел саен 26 нчы апрельдә шигырь бәйрәме була.

14. *Юкәләр, ак каеннар* ***алтыннан*** *киенде* (Г. Хәсәнов) җөмләсендәге билгеләнгән сүз – ***(2 балл)***

а) баш килештә;
ә) чыгыш килешендә;
б) урын-вакыт килешендә;
в) төшем килешендә.

15. *Әлбәттә,* ***барачак*** *алар, әлбәттә* ***очрашачак*** (А. Гыйләҗев) җөмләсендәге фигыльләр – ***(2 балл)***

а) үткән заманда;
ә) хәзерге заманда;
б) билгеле киләчәк заманда;
в) билгесез киләчәк заманда.

16. *Җиргә төрле төстәге чәчәкләр белән чуарланган яшел палас җәелгән* (Ш. Усманов) җөмләсендә ия булып килгән сүз – ***(2 балл)***

а) чәчәкләр;
ә) палас;
б) җиргә;
в) төрле.

## II Теоретик бирем.

Татар алфавитындагы парлы һәм парсыз тартык авазларны яңгырау һәм саңгырауларга бүлеп языгыз. ***(4 балл)***

Яңгырау тартыклар:
Саңгырау тартыклар:

## III Иҗади бирем.

Фатих Әмирханның “Ай өстендәге Зөһрә кыз” хикәясенә нигезләнеп, Зөһрә кыз турында 8-10 җөмләдән торган әкият (хикәя) языгыз. ***(10 балл)***